# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕБЕЗНЕ БАШЛЫЙБЫЗ!

## ЕЛМАЙ! БУ ДӘРЕС СИҢА ШАТЛЫКЛАР КИТЕРСЕН!

# ТҮБӘНДӘГЕ СҮЗЛӘРНЕ ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛЕП ЯЗЫГЫЗ. СҮЗЛӘРНЕ НИНДИ ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛЕП БУЛА? АЛАР НИЧӘ?

КҮГӘРЧЕН, МӘТРҮШКӘ, ЧЫРШЫ, АККОШ, КЕРПЕ, КЫЧЫТКАН, КӘҖӘ, КАЕН.

# ҮЗЕҢНЕ ТИКШЕР!

- **Кошлар: күгәрчен, аккош.**
- **Дару үләннәре: мәтрүшкә, кычыткан.**
- **Агачлар: чыршы, каен.**
- **Хайваннар: керпе, кәҗә.**

# СҮЗЛӘРНЕ УКЫГЫЗ. НӘРСӘ ҮЗГӘРДЕ?

җәй, җәй+ләр, җәй+ләр+ем, җәй+ләр+ем+не

күз, күз+ләр, күз+ләр+ем, күз+ләр+ем+нең

үлән, үлән+нәр, үлән+нәр+ем, үлән+нәр+ем+не

курчак, курчак+лар, курчак+лар+ым, курчак+лар+ым+ны

# ПОРЯДОК ПРИСОЕДИНЕНИЯ АФФИКСОВ К СУЩЕСТВИТЕЛЬНЫМ./ ИСЕМНӘРГӘ КУШЫМЧАЛАР ЯЛГАНУ ТӘРТИБЕ.

# КҮЗЛӘРНЕ ЯЛ ИТТЕРЕГЕЗ.

***Күзләр белән уңга, сулга, өскә, аска карагыз.***

***Күзләр белән түгәрәк, өчпочмак, квадрат ясагыз.***

***Тәрәзәгә еракка, якындагы предметка карагыз.***

# КУШЫМЧАЛАРНЫҢ ИСЕМНӘРГӘ ЯЛГАНУ ТӘРТИБЕ.

**ҖӘЙ+ЛӘР**

Күплек сан кушымчасы

**-ЕМ**

1 зат тартым кушымчасы - минем җәйләрем

**-НЕ**

килеш кушымчасы

АФФИКСЫ ПРИСОЕДИНЯЮТСЯ К ОСНОВЕ СУЩЕСТВИТЕЛЬНОГО В СЛЕДУЮЩЕМ ПОРЯДКЕ: СНАЧАЛА – АФФИКС ЧИСЛА, ЗАТЕМ АФФИКС ПРИНАДЛЕЖНОСТИ И ПАДЕЖНЫЙ АФФИКС:

КҮЗ + **ЛӘР** + **ЕМ** + **НЕҢ**,
КУРЧАК + **ЛАР** + **ЫМ** + **НЫ**.

# СҮЗЛӘРНЕҢ КУШЫМЧАЛАРГА ДӨРЕС АЕРУНЫ ТИКШЕР. ХАТАЛАРЫҢ БУЛСА, ТӨЗӘТ.

КҮЛМӘК, КОШЧЫГЫМ – КОШЧЫ(К)Г-ЫМ, ЧЫПЧЫКЛАРЫМ – ЧЫПЧЫК-ЛАР-ЫМ, ҖИЛКӘМӘ – ҖИЛКӘ-М-Ә, ҖИЛКӘМНЕ – ҖИЛКӘ-М-НЕ.

# ЙОМГАКЛАУ.

Нәрсәләр белдегез?

Нәрсә авыр булды?

# ӨЙ ЭШЕ.

Дәреслекнең 75 нче биттәге 4 нче күнегүдәге 4 нче  җөмләне укыгыз һәм шарлар, курчагымны, һавага сүзләрен кушымчаларга аерып языгыз.

- ***Сез яхшы, акыллы балалар! Көннәрегез уңышлы үтсен! Сау булыгыз!***